**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 30 апрель № 273

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының химик һәм биологик куркынычсызлык системасы» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 24 сентябрь, 672 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының химик һәм биологик куркынычсызлык системасы» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының химик һәм биологик куркынычсызлык системасы» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 24 сентябрь, 672 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының химик һәм биологик куркынычсызлык системасы» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 10 747 613,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 420 719,0 мең сум;<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп ителә торган бюджеттан тыш чыганаклар – 10 326 894,0 мең сум |

(мең сум)

| Ел | Барлыгы | Шул исәптән акча | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | бюджеттан тыш чыганаклар (предприятиеләр һәм оешмалар акчасы) |
| 2015 | 1 722 627,0 | 65 266,0 | 1 657 361,0 |
| 2016 | 2 682 322,6 | 71 090,6 | 2 611 232,0 |
| 2017 | 1 643 768,6 | 71 090,6 | 1 572 678,0 |
| 2018 | 1 547 794,6 | 71 090,6 | 1 476 704,0 |
| 2019 | 1 562 322,6 | 71 090,6 | 1 491 232,0 |
| 2020 | 1 588 777,6 | 71 090,6 | 1 517 687,0 |
| Барысы | 10 747 613,0 | 420 719,0 | 10 326 894,0 |

Финанслау күләмнәре фараз характерында һәм тиешле бюджетлар мөмкинлегеннән чыгып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.»;

Программаның II бүлегенең унтугызынчы абзацын төшереп калдырырга;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 10 747 613,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән– 420 719,0 мең сум, билгеләнгән тәртиптә җәлеп ителә торган бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән – 10 326 894,0 мең сум

(мең сум)

| Ел | Барлыгы | Шул исәптән акча | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | бюджеттан тыш чыганаклар (предприятиеләр һәм оешмалар акчасы) |
| 2015 | 1 722 627,0 | 65 266,0 | 1 657 361,0 |
| 2016 | 2 682 322,6 | 71 090,6 | 2 611 232,0 |
| 2017 | 1 643 768,6 | 71 090,6 | 1 572 678,0 |
| 2018 | 1 547 794,6 | 71 090,6 | 1 476 704,0 |
| 2019 | 1 562 322,6 | 71 090,6 | 1 491 232,0 |
| 2020 | 1 588 777,6 | 71 090,6 | 1 517 687,0 |
| Барысы | 10 747 613,0 | 420 719,0 | 10 326 894,0 |

Финанслау күләмнәре фараз характерында һәм тиешле бюджетлар мөмкинлегеннән чыгып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

2016 елга Татарстан Республикасы бюджетыннан планлаштырылган акча «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2015 елның 19 ноябрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кертелгән һәм хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, күзәтүсез хайваннарны тоту һәм карау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак авырулардан саклау буенча чаралар үткәрүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр булып тора.

Программаны бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән финанслау күләмнәре предприятеләр һәм оешмаларның химик һәм биологик куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларына фаразланган чыгымнары нигезендә формалашкан. Чаралар күзлегеннән чыгып Программаны финанслау күләмнәре турында җентекле мәгълүмат әлеге Программага кушымтада китерелә.»;

Программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков